РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ПЕТРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.06.2019 № 40

**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Петровка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 9 апрелендә чыгарган «Капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 35нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Законга туры китерү максатында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Петровка авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең 2019 елның 9 апрелендә чыгарган «Капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 35нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 бүлекнең 5.8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип табылганда, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, Башкарма комитет, күпфункцияле үзәк, оешма яки 210нчы Федераль законның 16нчы маддәсенең 1.1нче өлешендә каралган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында, алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

2. Карар текстының калган өлешен үзгәрешсез калдырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Ф.Ибрагимов**